وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№25 (142). 22 июнь 2012 / 3-шәгъбан-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Әлмәттә балалар өчен җәйге дини курслар үтә ▷2◁



Мәгариф һәм дин ▷2◁



Кавемен белгән диненнән, теленнән, милләтеннән ваз кичмәс ▷3-4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ТАТАРСТАНДА 25 ИЮНЬНӘН 1 ИЮЛЬГӘ КАДӘР МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕНЕҢ АЛТЫНЧЫ ФЕСТИВАЛЕ УЗА**

Әлеге фестивальнең максаты - өммәт эчендәге проблемаларны хәл итү өчен, мөселман яшьләрен берләштерү, алар арасында хезмәттәшлек урнаштыру.

Чара ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Татарларның федераль милли-мәдәни мөхтәрияте, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, "Идел" яшьләр үзәге ТР Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе теләктәшлегендә оештырыла.

Мөселман яшьләре диспутларда, "түгәрәк өстәл" утырышларында, лекцияләрдә, бәйгеләрдә һәм Ислам буенча дәресләрдә катнаша алачак. Шулай ук дин әһелләре белән очрашулар, экскурсияләр каралган.

Берничә ел дәвамында фестиваль Болгар шәһәрендә оештырылып килде. Быел аны үткәрү урыны итеп Казаннан 30 чакрым ераклыкта урнашкан "Идел" яшьләр үзәге билгеләнгән. Оештыру комитеты форумда катнашу өчен 18-30 яшьләрдәге актив мөселман яшьләрен чакыра. Алар үз төбәкләрендәге мөселманнар тормышын һәм мөселман оешмалары эшчәнлеге турында кызыклы чыгышлар ясар, дип көтелә.

**КАЗАНДА "ДИН ҺӘМ БҮГЕНГЕ ДӘҮЛӘТНЕҢ КОНСТИТУЦИОН ХОКУКЫ" ДИП АТАЛГАН "ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ" УТЫРЫШЫ УЗАЧАК**

30 июньдә Казан (Идел буе) федераль университетының юридик факультеты Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә "Дин һәм бүгенге дәүләтнең конституцион хокукы" дип аталган "түгәрәк өстәл" утырышы уздыра. Әлеге чара ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Коръән елы кысаларында КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе залында үткәрелә.

"Түгәрәк өстәл" утырышында ТР Президенты Аппараты, Дәүләт Советы, ТР Югары суды, ТР Прокуратурасы, Россия ислам университеты, Казан Епархиясе, Иран, Төркия консуллыклары вәкилләре катнашуы көтелә. Чарага Казан университеты галимнәре, конституцион хокук һәм дин буенча белгечләр чакырулы. Сөйләшү барышында Россиянең бүгенге конституцион хокуклар кырында дини оешмалар һәм дәүләт арасында үзара хезмәттәшлекне камилләштерү концепциясен эшләүгә кагылышлы проблема күтәреләчәк.

**АРЧА ШӘҺӘРЕНДӘ ТАГЫН БЕР МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ**

Арча шәһәренең станция өлешендә Изгеләр мәчете ачылды. Анда ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, республиканың баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Арча муниципаль районы җитәкчесе Алмас Нәзиров, район имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗев, дин әһелләре катнашты. Әлеге мәчет иганәчелек ярдәме белән төзелгән.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу дәвам итә. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# ШӘГЪБАН АЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

*Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү! Мөхтәрәм дин кардәшләребез!*

**2012 елның 20 июнендә шәгъбан ае башланды. Шәгъбан - ай календаре буенча сигезенчесе, мөселманнар өчен мөбарәк булган өч айның берсе. Ул рәҗәп аеннан соң килеп, изге Рамазан аена якынлашуны кисәтә һәм аңа рухи яктан безне әзерли. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) бу мөбарәк айны аеруча кадерләгән.**





Пәйгамбәребез (сгв) шәгъбан турында: "Рәҗәб аеның башка айлардан өстенлеге - башка кешеләр сөйләменнән Коръән сүзләре өстенлеге кебек үк. Шәгъбан аеның башка айлардан өстенлеге - минем башка пәйгамбәрләрдән өстенлегем кебек. Ә Рамазан өстенлеге - Аллаһның Үзе барлыкка китергән адәм балаларыннан өстенлеге кебек", - дигән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) шәгъбан ае рухи ныклыкка ирешү юлында, тормышыбызны изге гамәлләр белән баетып һәм Рамазан Шәриф ае алдыннан үзебезнең көчебезне арттырып үткәрергә безнең өчен зур этәргеч булып торуын искәртә.

Бу айда иң яхшы гамәлләрнең берсе булып ураза тоту санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әлеге айда һәрвакытта да ураза тоткан. Госман ибн Зәит җиткергәнчә: "Аллаһның Илчесе Мөхәммәд Пәйгамбәрдән (сгв) сорадым: "Йә Расүлүллаһ, синең шәгъбан аеннан да күбрәк ураза тотканыңны күргәнем юк". Пәйгамбәребез (сгв) җавап бирде: "Бу ай рәҗәп һәм Рамазан арасында, еш кына бу хакта кешеләр оныта. Бу айда бөтен гамәлләр дә Аллаһы Тәгаләгә күтәрелә. Гамәлләрем күккә ашканда мин уразада булырга телим". Шуңа да әлеге айны ураза тотып һәм гыйбадәттә үткәрүебез Аллаһка һәм аның Илчесенә (сгв) булган мәхәббәтебезне күрсәтә. Шәгъбан аенда изге гамәлләр кылып, ураза тотып, сөннәтебезгә тугрылыклы булуыбызны күрсәтәбез, шуның белән исә ахирәт көненә үзебезгә зур бүләкләү әзерлибез. "Шәгъбан ае, - ди сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв), - тәмуг утыннан саклый. Минем белән очрашырга теләге булган һәркем кимендә өч көн булса да ураза тотсын". Шулай да Рамазан уразасы алдыннан ял итү, Рамазанның фарыз уразасы нәфел уразалардан аерылсын өчен, шәгъбан аеның икенче яртысында ураза тотмаска киңәш ителә.

Шәгъбан аеның исеме гарәпчә "тәшәгабә" дигән сүздән килеп чыккан, ул "тарала" дигән мәгънәне белдерә, ягъни бу айда тыелганнардан тыелып, Аллаһ ризалыгы өчен кылган изгелекләребез арта һәм дөньяга тарала. Сәхабәләр әлеге айда, ураза тоту һәм төнге намазлардан кала, сәдака бирергә һәм ифтарлар үткәрүгә ярдәм итәргә ашыкканнар. Аларның гамәлләре бүгенге көндә дә һәрберебез өчен үрнәк гамәл булып торса иде.

Шәгъбан аенда бер изге кичә бар - Бәраәт кичәсе, ягъни "ләйләтул-Бәраәт". Бу айның 15 нче кичәсе - гөнаһлардан котылу, бәхет һәм иминлек, төрле уңышлар, изгелекләр иңә торган кич. Җәбраил фәрештә пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (сгв) әлеге кич турында болай дип җиткерә: "Әлеге кичтә Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә өч йөз рәхим-шәфкать ишеген ача һәм барлык кешеләрнең - имансыз, көнче, гайбәтче, спиртлы эчемлекләр эчүче, туганнары белән араларын өзүче, ата-аналарының сүзләреннән чыккан, зина кылучылар, тәкәббер, фетнә чыгаручылардан кала, гөнаһларын ярлыкый. Үзләре тәүбәгә килеп, хәрәм эшләрдән тыелмый торып, алар Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавына ирешә алмаячаклар".

Шәгъбан ае Аллаһның рәхимшәфкатенә ирешү һәм рухи ныклыгыбызны ныгыту өчен янә бер мөмкинлек булып тора, пәйгамбәребез Мөхәмммәднең (сгв) сөннәте буенча, әлеге изге айдагы гыйбадәтнең әһәмиятлелеген аңларга һәм барыбыз да мөмкинлектән файдаланып калырга ашыгыйк.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# "ДУМ РТ ХАДЖ" – ТАТАРСТАН МӨФТИЯТЕНЕҢ ХАҖ ПРОГРАММАСЫ

**Мөселман кешесе һәрвакыт руханилар белән бәйләнештә торырга тиеш. Баланы тугач ук исем кушу йоласын үткәрү өчен мәчеткә алып киләләр, шунда ук никах укыталар, бәйрәмнәргә һәм киңәш сорарга киләләр.**

Хаҗ - ул хәленнән килгән һәр мөселман кешесе башкарырга тиешле йолаларның тулы бер комплексы. Ләкин һәрбер мөселманның аны башкарырга мөмкинчелеге булмау сәбәпле, хаҗ һәм аның үзенчәлекләре турында аз кеше белә. Шуңа күрә беренче тапкыр хаҗга барырга җыенган мөселманны төрле сораулар борчый башлый: киңәш сорап кемгә мөрәҗәгать итәргә - махсус туристик фирмаларгамы, әллә мәчеткәме?

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте - Татарстан мөфтияте - бу проблеманы хаҗ мәсьәләләре бөлән махсус шөгыльләнгән структураны ачып хәл итә.

**"ДУМ РТ ХАДЖ"**ның региондагы үсеше җитәкчесе Талиев Габдулла Камил улы сүзләренә караганда, бу шулай булырга тиеш тә: "Хаҗ кылу кебек җаваплы эш мөфтият күзәтүе астында булырга тиеш".

**"ДУМ РТ ХАДЖ"**ның башкаручы директоры Әбу Оун Хәлил Ибраһим улы хаҗга баруны оештыру белән берничә ел шөгыльләнүе турында һәм бүген "ДУМ РТ ХАДЖ" хаҗиларга мөмкин булган кадәр җайлы шартлар тудыра алган Согуд Гарәбстанының берничә оешмасы белән килешү төзүләре турында хәбәр итте.





- Без Мәккәдәге әл-Хәрам мәчетеннән ерак булмаган кунакханә белән килешү тезедек. Һәркөнне 5 тапкыр намаз вакытларында кунакханәдән мәчеткә автобус йөриячәк. Кунакханәдә барлык шартлар да тудырылган: ашау-эчү, телевидение, радио, намаз уку өчен бүлмәләр, медиклар бар. Моннан тыш, Татарстаннан килүчеләр өчен татар ашлары әзерләнәчәк, чөнки

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Әлмәттә балалар өчен җәйге дини курслар үтә

**Быелгы җәй башы балалар өчен җәйге ислам курсларын оештыруда бик уңай вакыт булды. Әлмәт районының мәчет-мәдрәсәләрендә берничә җәйге ислам курслары уңышлы тәмамланып, үзләренә тагын да күбрәк балаларны җәлеп иттеләр. Июнь аенда шәһәрнең Үзәк мәчетендә, Иске Әлмәттәге 1 нче мәхәлләдә, Урсаладагы 8 нче мәхәлләдә (Нурсала мәчете), Әлмәт ислам мәдрәсәсенең кызлар бүлегендә 6 яшьтән 15 яшькә кадәрге балалар өчен ислам динен өйрәтү буенча курслар булып узды.**



Укыту эшләрен Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Әлмәт ислам мәдрәсәсе шәкертләре алып барды. Көндезге курслар 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр дәвам итте. Биредә төш алдыннан балалар дин гыйлемнәрен өйрәнделәр, төштән соң алар кызыклы уеннарда катнаштылар, шәһәр паркында ял иттеләр, экскурсияләргә, роллердромга йөрделәр.

Шуны әйтәсе килә, кайбер мәчетләр өчен балалар өчен җәйге курслар үткәрү яхшы традициягә әйләнеп бара. Мәсәлән, Әлмәтнең Үзәк мәчете һәм Әлмәт ислам мәдрәсәсенең кызлар бүлеге барлыкка килгән вакыттан ук балалар өчен шундый чаралар үткәргәннәр һәм хәзер бу җәйге курслар аларның йөзек кашы булып тора.

1 нче мәхәллә - Әлмәтнең иң иске мәчетләренең берсе. Элекке елларда ул матур исем йөрткән - Яшел мәчет. Бүгенге көндә ул бик уңышлы эшләп килә, ә балалар өчен җәйге ислам курслары биредә 2007 елдан бирле оештырыла. Нурсала мәчете исә балаларны укыту-тәрбияләү эшләре белән 2010 елдан башлап шөгыльләнә.

Кыска гына вакытка мәчет заллары, укыту бүлмәләре тынып калды. Шаугөр килеп, көлеп йөрүче балалар яңа белемнәр алып, әдәп-әхлакка өйрәнеп өйләренә таралышты. Ләкин моның белән генә бетмәде, мәчет-мәдрәсәләрдә курслар дәвам итә. Нурсала мәчетендә ир балалар өчен яңа курслар башланып китте, алар 15 июньнән 30 июньгә кадәр дәвам итәчәк.

Түбән Мактама бистәсенең Марс мәчете дә балалар өчен ишекләрен ачты: кыз балалар өчен курслар 16 июньнән алып 25 июньгә кадәр, ир балалар өчен 2 июльдән 11 июльгә кадәр узачак.

Шулай ук кечкенә мөселманнарны кунакка Техснаб бистәсендә урнашкан 7 нче мәхәллә мәчете чакыра. Биредә ир балалар өчен курслар 20 июньнән 6 июльгә кадәр оештырылачак.

Әлбәттә, Әлмәт ислам мәдрәсәсе дә артта калмый. 18 июньдә кызлар бүлегендә 10-15 яшьлек кыз балалар өчен Коръәнне өйрәнү буенча курслар башланып китте. Бу курслар 15 июльгә кадәр дәвам итәчәк, дип игълан ителде. Шулай ук 6 августтан 19 августка кадәр биредә 15-25 яшьлек кызлар өчен Коръәнне өйрәнү буенча курслар оештырылачак.

Язгы чәчүләр үтте, ашлыклар утыртылды, мул уңышны көтәсе калды. Икмәкне тырышып утырткан кебек, җәйге ислам курсларында да балаларга белем орлыклары салалар, дини тәрбия бирәләр. Нинди уңыш җыясыбыз нәкъ менә балаларыбызны ничек итеп тәрбияләүдән тора ич! Аллаһ насыйп итсә, уңышыбыз мул булыр!

***Айрат ГАТАУЛЛИН,***
***Әлмәт муниципаль районы Советының Дини һәм иҗтимагый оешмалар белән элемтәләр бүлеге***

---

**Мәгариф сүзе "уку-укыту, белем бирү" дигәнне аңлата. Яшәү рәвешен, ягъни тормышны Аллаһы Тәгалә билгеләгән һәм ул динигә яисә дөньявига бүленми. Мәгариф, дин һәм дөнья бербөтен булганда гына җәмгыять тиешле үсеш ала. Шуның өчен ислам дине төрле биләмәләр яулап алып, халыкларны үзенә коллыкта тота торган империя түгел, бәлки югары әхлакка ия булган, техник-технологик яктан алга киткән, мәгърифәтле, дөньяда тиңе булмаган ислам цивилизациясе барлыкка китерә. Бу цивилизация, мәгарифе бер һәм бүленмәс булган вакытта, бөтен дөньяның байлыгына ия була һәм шул дөнья белән хакимлек итә.**

# МӘГАРИФ ҺӘМ ДИН

Әмма байлык һәм хакимлек үз эшләрен эшлиләр: гамәлләр дөньявига, ахирәтнекенә бүленә. Шул сәбәпле дин дә төрле фиркаләргә таркала, дөнья да патшалыклар кулына кала, Ислам дөньясы таркала, бербөтен булудан туктый. Мәгариф тә гамәлләргә карап динигә һәм дөньявига бүленә. Ислам цивилизациясе зәгыйфьләнә һәм ислам диненнән күп кенә сыйфатларны үзенә алган, нигезе дөньялыкка корылган Европа цивилизациясенә җиңелә, аңа бәйлелектә кала һәм бүген дә шул бәйлелектән чыга алмый. Бу хәл Казан ханлыгы белән дә шулай ук була. Империя кул астында калган татар мөселманнарына дини һәм дөньяви белем белән шөгыльләнү рөхсәт ителми. Ул яшерен рәвештә булса да гыйбадәтен үти, тормышын дингә таянып алып бара, шуңа күрә ул ислам динен өйрәнергә, җәмгыять әһелләренә өйрәтергә мәҗбүр була. Димәк, татар халкының мәгарифе империя шартларында да сакланып кала. Шушы чорларда татарларга суфичылык керә һәм диннең империя шартларында сакланып калуына, хәтта күтәрелүенә, ягъни дини мәгарифнең үсүенә зур роль уйный. XIX гасырда дөньяда бара торган үзгәрешләр татар мөселманнарына да тәэсир итә. Мәдрәсәләрдә дини белем белән бергә дөньяви белем дә укытыла башлый. Югары уку йортлары дәрәҗәсендә белем бирә торган мәдрәсәләр



барлыкка килә. Ягъни сакланып калган дини мәгарифкә дөньяви мәгариф килеп керә. Шул мәдрәсәләрдә укып бөтен дөньяга танылган дин галимнәре, фән галимнәре һәм дәүләт эшлеклеләре барлыкка килә. Әмма дини мәгарифкә килеп кергән дөньяви мәгариф, илдә булган инкыйлаб сәбәпле дә, тиз арада мәгариф системасыннан дини өлешен кысрыклап чыгара һәм бу үз чиратында диннең бетүенә, ахыр чиктә халыкның иң элек гореф-гадәте, аннары әхлагы, теле һәм үзенең дә бетү дәрәҗәсенә төшүгә сәбәп була.

Мәгарифнең динигә һәм дөньявига бүленмәве - ул алтын урталык. Бүгенге көндәге мәгариф системасы совет динсез мәгариф системасының варисы. Ул дөньяви белемне генә үз эченә ала һәм аның берничек тә дини белемне үзенә кабул итәсе килми. Ул Аллаһы Тәгаләнең, бөтен дөньяларның, шул исәптән кешенең дә Раббысы булуын танымый торган эволюцион теориягә нигезләнгән. Шуңа күрә дә сүздә "динне балалардан укыта башларга кирәк" дип әйтелсә дә, гамәлдә мәктәпләргә "Дөньяви әхлак" кертелү белән генә чикләнелә (анысын да дин әһеле укытырга тиеш түгел дигән шарт белән).

Динне дөрес аңламау, Аллаһы Тәгаләне Раббы дип танымау, бүгенге мәгариф системасын икегә бүлергә, ягъни дини һәм дөньяви мәгариф системасына бүлергә мәҗбүр итә. Бу дини мәгарифкә дә, дөньяви мәгарифкә дә файдалы түгел, һәм нәтиҗәдә, милләтнең үсешен түгел, бәлки аның үлемен генә якынайта.

Республикада рәсми мәгариф системасы зур тәҗрибәгә, көчле финанслауга нигезләнгән булуга карамастан, тиешле нәтиҗә бирми: җәмгыятьнең тиешле дәрәҗәдә алга китүен тәэмин итми - җәмгыятьтә эчкечелек, зина, ришвәтчелек, җинаятьчелек һ. б. тискәре күренешләр чәчәк ата.

Сүздә дин иреге булса да, чынлыкта динне йола рәвешендә генә тотарга тырышу, мулла вазифасының официаль статусы булмавы, һаман да "мулла бабай" гына булып калуы, дини мәгарифнең дә тиешле үсеш алмавына сәбәп булып тора. Мәхәллә бар, мәчет бар, ә тиешле хезмәт хакы ала торган, тиешле тормыш шартлары белән тәэмин ителгән, халыкны тиешле әхлакта тәрбияли торган имам вазифасы юк. Туучыларның аз булуы һәм үлүчеләрнең күп булуы сәбәпле, бүгенге көндә имамнарның төп вазифасы булып күмү белән генә бәйле йолаларны башкару тора. Бүген җәмгыятьтә шундый муллалар гына таләп ителә. Әгәр дә мәгарифкә мөнәсәбәт үзгәрмәсә, тиздән милләтнең үзенә дә искә алу мәҗлесләре генә үткәрәсе кала.

Әгәр дә милләтебез алга китсен дибез икән, дәүләт мәгариф системасын үзгәртергә, анда дини компонент кертергә кирәк. Россия Конституциясе моңа мөмкинлек бирми дип әйтүчеләр руслар төп халкы булган өлкәләргә карасыннар. Анда күптәннән инде христиан дине кертелгән.

Дин дәүләттән аерылган булу сәбәпле дини һәм дөньяви мәгарифнең бердәмлеген без хәл итә алмыйбыз. Инде аерылган икән, безгә дини мәгарифне дөньяви мәгариф дәрәҗәсенә җиткерергә кирәк. Бәлки шул вакытта дөньяви мәгариф үзе дини мәгарифкә кушылырга теләр. Ә бу проблеманы юнәлешләре бертөрле булмаган 80 мөфтиятнең 80 мәгариф системасы белән хәл итеп булмый.

Динебездәге төрлелек 1988 елдан, үзгәртеп кору белән бергә башланды. Шушы вакыт эчендә җәмгыятебезгә ислам дине исеме белән бик күп юнәлешләр керделәр. Алар халык арасында тамыр җәеп өлгерделәр. Барысы да үзләрен хәнәфи мәзһәбен тотучы традицион дин итеп күрсәтергә тырышалар. Традицион дигән сүз үзе үк аңлашылып бетми. Әгәр дә XIX гасырга кадәр булса, ул - суфичылык, ягъни кадимчелек, әгәр дә XIX гасырдан соң булса - ваһһабчылык, ягъни җәдитчелек. Традицион дин дип күп сөйләүчеләр традицион диннең бөтен мәгънәсен мәетнең "өчесе"н, "җидесе"н, "кырыгы"н, "елы"н һәм Мәүлед бәйрәмнәрен үткәрүгә кайтарып калдыралар. Шулар ук мәдрәсәләрдән Г.Курсави, Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхреддин кебек галимнәрнең хезмәтләрен өйрәнүне, куллануны, аларның эшен дәвам итүче галим-муллалар хәзерләүне таләп итәләр. Ә бит бу галимнәр динебезне? традиционалълеген күрсәтә торган, алда санап кителгән йолалар белән риза булмаганнар гына түгел, бәлки аларга каршы көрәшкәннәр. Бер үк вакытта җәдитче дә, кадимче дә булып булмый.

Әгәр дә татар халкы сакланып калсын дип әйтәбез икән, бөтен Россия җирлегендә бер юнәлеш булырга тиеш. Татарстанда бер, Башкортстанда икенче, Самарада өченче була алмый. Бердәм мөфтият буламы-юкмы, әмма Россиядә татарларның бер дини юнәлештә булган бер дини мәгариф системасы булырга тиеш. Ә шәкерт, укытучы, финанс, уку-укыту программалары һ. б. бик күп проблемалар - алар барысы да безнең таркаулыктан гына.

***Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәте Президиумы әгъзасы, Кама буе төбәге казые***

# Кавемен белгән диненнән, теленнән, милләтеннән ваз кичмәс

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәлгаакыйбәтү лил-мүттәкыйн. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһии вә сахбиһии әҗмәгыйн! Әссәләәмүгаләйкүм вә рахмәтуллааһи вә бәракәәтүһ!**

Нәсел шәҗәрәсе төзү (фәнни термин белән әйткәндә, генеалогия) сәнгате - Идел Болгары дәүләте мәдәниятенең мөһим бер өлеше. Тарихи шәхесләрнең, аларның фамилияләренең туганлык элемтәсен өйрәнүче татар галиме Марсель Әхмәтҗанов сүзләренә караганда, "туганлык элемтәләре" дигән сүзнең төп мәгънәсен "шәҗәрә" ("нәсел агачы") дигән сүз белдерә. Бу - гарәп термины. Әмма бу шәҗәрә төзүне татарлар гарәпләрдән алган дигән сүз түгел. Әлеге эшне безнең бабаларыбыз үзләре башлаган һәм ул алардан безгә калган мирасыбыз булып тора.

Шәҗәрә - нәсел агачы, бабаларыбызның әллә ничә буынга кадәр исемнәрен белү дигән сүз. Элек-электән нәсел тамырларын буыннан-буынга барлап, нәсел шәҗәрәсен төзү гадәти күренеш булган. Шәҗәрә аркылы халык ата-бабаларының дәвамчысы булуына төшенгән. Ислам дине буенча, һәрбер татар кешесе, 7 буынга кадәр этисе, әнисе ягыннан булган әби-бабаларының исемнәрен тәртибе белән белеп, дога кылырга тиеш. Нәсел агачының белү, эзләү, төзү - барыбызның да изге бурычы.

Татар шәҗәрәләре, нәсел тарихы булу белән бергә, милләтебезнең юридик документлары булып та саналган. Аларга карап заманында Россия хөкүмәте дә татар биләре, тарханнары һәм морзаларының милеккә хокукларын таныган.

Илен белмәгән - игелексез, халкын белмәгән - холыксыз, нәселен белмәгән - нәсәпсез, дип халык юкка гына әйтмәгән. Адәм баласы үзенең 7 буын бабасын белергә тиеш, дигән борынгылар. Шул вакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының, үз халкының чыгышын белә. Менә шул тәртиптә без үзебезнең шәкертләрне тәбияләргә тырышабыз да.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе - югары һөнәри дини белем бирә торган уку йорты. Безнең төп максат - җәмһүриятебез һәм Рәсәйнең татар төбәкләре өчен мөмкин кадәр күбрәк яхшы белемле имамнар әзерләү.

Мәдрәсәбездә татар телен укытуга таләп зур, чөнки шәкертләребез татар халкы яшәгән мәхәлләләр өчен әзерләнә. Алар татарча матур итеп вәгазь сөйли белмәсә, халык белән аралаша алмаса, әлбәттә, үз урыннарын таба алмаячак. Шәкертләрне ата-бабадан килгән имам Әгъзам Әбү Хәнифә хәзрәтләре мәзһәбендә тәрбиялибез. Бер үк вакытта милли һәм дини мирасыбызга, гореф-гадәтләребезгә, милли киемнәребезгә карата да алар күңелендә мәхәббәт тәрбияләргә тырышабыз.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*



# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ҖАН СЕРДӘШЕ – ЙОСЫФ КИТАБЫ

**(Ахыры. Башы газетабызның 15 июнь (№ 24) санында.)**



Эпик башлангыч Йосыф сурәтен тулыруның бүтән якларында да чагылыш таба. Каһарманның үзен рәнҗеткән агаларына карата олы җанлылык күрсәтүе сюжетның тәүге чыганакларында ук урын алса да, төрки поэмада ул герой проблемасын хәл итүнең башка аспектлары белән тыгыз бәйләнештә бирелә, ягъни идеаллаштыруның эпик кануннарына туры килә. Төрки эпосның нинди генә сюжетын алсаң да, каһарманның олы җанлылыгы даими күренеш буларак тасвирлана.

Зөләйхә сурәтенең нигезендә дә эпик башлангыч ята. Кол Гали бу сурәткә мөһим социаль-әхлакый вазифа йөкли, шунлыктан аның иҗат ихтыяры монда аеруча көчле сизелә.

Мәгълүм булганча, Тәүрат белән Коръәннән башлап, сюжетның барлык җитди чыганакларында Мисыр газизенең хатыны (Асенат, Т.Манда: Мутеменет; "Зөләйхә" исемен башлап Фирдәүси бирә) бары Йосыфка бәла-каза китерүче тискәре сурәт буларак гәүдәләнә. Аны уңай образ итеп иң әүвәл Фирдәүси эшли. Хәлбуки бөек фарсы шагыйрендә дә сурәт каршылыклы кала. Беренчедән, ул үзе, ир хатыны була торып, Йосыф каршында коточкыч әдәпсезлек күрсәтә. Икенчедән, Йосыфның инде аңа өйләнгәндә кәнизәктән ике баласы туган була. Фирдәүси поэмасында Зөләйхә "кыйбти хатын", ягъни Мисыр кешесе итеп бирелә.

"Әнисел-мөридин"дә китерелгән бер риваять буенча, Зөләйхә - башка ил патшасының кызы. Үзенең бу ягы һәм Йосыфка аны төштә күреп гашыйк булуы, сөеклесе артыннан бүтән патшалыкка китүе белән дастаннар традициясендә тәрбияләнгән төрки шагыйрь күңеленә ул хуш килә. Көнчыгыш поэзиясе тарихында беренче буларак, Кол Гали сюжетның мәхәббәт сызыгын гыйшык дастаннары схемасына кора. Кыз Мисырга алдан ук төштә күргән Йосыфы өчен килгәч, соңыннан газиз хатыны була торып, "әрсезлек" күрсәтүе һәм әхлакый, һәм психологик яктан тулысынча аклана. Шул рәвешле, Кол Гали сурәтне эчке каршылыктан тәмам азат итә.

Аның әсәрендә Зөләйхә - Йосыфның бердәнбере. Шагыйрь бу фикерне ассызыклап әйтә. Әсәрнең каһарманнары мисалында мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләсен хәл итеп, ул үз чоры Көнчыгышындагы күп хатынлылыкка каршы чыга.

Атасы Йагъкуб белән очрашкач, Йосыфның балаларын бабалары каршына китергәндә әйткән сүзләре мәгълүм дәрәҗәдә ата белән угылның тормыш принципларын каршы кую булып та яңгырый.

*Андин дагый Йосыфның угланлари,*
*Йагъкуб сурдый Йосыфдан һәм анлари,*
*Йосыф әйдер: "Угланларим безим бари -*
*Җөмләси Зөләйхәдән улур имди".*

Зөләйхә вафатыннан соң да шагыйрь аларның мәңгелек тугрылыгына басым ясый.

Андин соңра Зөләйхә вафат улди,
Йосыф аның хәсрәтилә мәгъмум улди,
Андин соңра айрук йәнә ивләнмәди,
Угланлари башарубән ирәр имди.

Шул рәвешле, шагыйрь бердәнбер мәхәббәт һәм хатын идеясен алга сөреп, каһарман һәм гомумән Йагъкуб гаиләсе өстенә килгән бәла-казалар, кардәшләрнең ата мәхәббәтен бүлешә алмыйча ызгышулары - барысы да күп хатынлылык бәласе дигән фикерне үткәрә. Поэзиядә Йосыф сюжетын эшкәртү тарихында бу яктан беренче юл яручы була ул.

Зөләйхә сарае - автор фантазиясенең байлыгына бик әйбәт дәлил. Сарай бизәлешен тасвирлаганда, Гол Гали үзенең Көнчыгыштагы әлгәреләреннән шактый мөстәкыйль эш иткән. Әсәрдә аерым мотивлар Фирдәүсидән һәм "Әнисел-мөридин"нән алынса да, бизәлешнең әхлакый-эстетик һәм башкарылыш яклары гаять үзенчәлекле. Барыннан да элек, шагыйрьнең төрки укучы каршында үтә дә әдәп саклавы күзгә ташлана. Фирдәүсидә Зөләйхә Йосыфны тәхеттә ялангач утырып каршылый, һәм Йосыф, күзен кая төбәсә дә, көзгеләрдә аның чагылышын күрә. "Кыйссаи Йосыф" авторы исә үсемлек, кош-корт һәм хайван сурәтләренә киң урын бирә.

Сарай нәкышенең композиция һәм фактурасында эпик башлангыч өстенлек итә. Алтын агачларга кунган кошлар, ул агачлар янында иярле алтын ат, көмеш үгезләр борынгы төркиләрнең ышануларына һәм мәҗүсилек чоры сәнгатенә барып тоташа. Бизәлештәге үзәк мотивларга төрки дастаннардагы нәсел агачы тасвире күчерелгәнлеген күрү читен түгел. Казан татарларының чигү сәнгатендә нәсел агачының ике ягына утыртып ясалган алтын яисә көмеш кош сурәтләрен соңгы чорларга кадәр күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, калфакка чигелгән шушындый сурәт бик кызыклы. Түбәсенә алтын һәм көмеш кәккүк кунган, алтын һәм көмеш яфраклы тирәк төбенә бәйләп куелган алтын төкле ат алтай эпосының борынгыдан килә торган тотрыклы мотивы санала.

Йосыфның идарәсен шагыйрь байга да, ярлыга да тигез караучы "идеаль" итеп тасвирлый. Бу - асылда Йосыф Баласагунлыдан башлап, татар әдәбиятында мәгърифәтчеләргәчә дәвам иткән прогрессив-демократик, әмма хыялый-утопик идея. Кол Гали аңа үзенчәлекле төсмер өсти: ул илдәге идарә гадел булсын өчен, хөкемдар түбәннән, халык күргән мәшәкатьләрне үзе кичереп күтәрелергә тиеш дип саный. Бу исә татар мәкалендәге "Карадан чыккан хан яхшы" дигән фикергә аваздаш.

Гадел идарә өчен хөкемдарның түбәннән күтәрелү зарурлыгын шагыйрь вәзир эпизоды белән кабат раслый. Йосыф тәхеткә утыргач, аның вәзире мәсьәләсе килеп баса. Каһарман сәйранга чыкканда беренче очраган кешене үзенең вәзире итәргә була һәм шулай эшли дә. Ул, үтә йолкыш, кыяфәтсез, фәкыйрь бер кешегә юлыгып, шуны вәзир итә. Вәзир исә Йосыфка лаек акыллы һәм гадел булып чыга. Бу эпизод башлап Кол Галидә очрый. Мәсьәләнең хәл ителешендәге әкиятчелек беренче очраган кешене сайлап алуда чагыла. Моңа охшаш хәлне бик күп татар әкиятләрендә күрергә мөмкин.

* * *

"Кыйссаи Йосыф" поэмасы әдәбият тарихының ялгыз бер күренеш түгел, ул үзенә кадәрге әдәбият үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килеп, аннан соңгы төрки әдәбият үсешенә дә йогынты ясаган әсәр. Аның эчтәлеге нинди чыганаклардан алынуын билгеләү һәм сәнгатьчелеккә йогынты ясаган факторларны ачу әдәбият тарихында традицияләр формалашуны күз алдына китерү өчен дә мөһим.

Эпик башлангыч поэманың стилендә дә өстенлек итә. "Кыйссаи Йосыф"ны шул сюжетка язылган барлык әсәрләр арасында аерып торган мөһим үзенчәлек - ул сөйләмнең диалогка корылуы. "Йагъкуб әйдер", "Йосыф әйдер", "Зөләйхә әйдер" кебек композицион-стилистик ялгамнар, һичшиксез, төрки халыклар фольклорындагы әйтешләргә һәм дастан поэтикасына барып тоташа.

Кол Гали персонажларны ике гомумилеккә: уңайга һәм тискәрегә генә аера. Каһарманнарның уңай булуына беренче шарт итеп ул зирәклекне куя. Табигый ки, андый персонажларның теле дә афористик.

Афоризмнар башлыча Йосыф һәм Йагъкуб сөйләменә хас. Зөләйхә күргән төштә каһарманның сабырлык турында биргән киңәше афористик формада Йагъкуб телендә дә, сарай хезмәтчеләренең Зөләйхәне юатуларында да үзгәрешсез диярлек кабатлана: "Сабыр берлә морад хасил улур имди". "Сабыр иткән морадына җиткән" дигән татар мәкале дә башлап Кол Гали поэмасыннан алынган булса кирәк.

Үз-үзен тотышындагы акыллылык һәм афористик тел Йосыфның үзен рәнҗетүчеләр каршында өстенлеген, вакыйгалардан югары була белүен күрсәтә. Мәсәлән, аны коллыкка саткан агалары турында ул сәүдәгәргә: "Һәр кеши үз лайыкын эшләр имди", - дип җавап бирә. Ә Малик Дугырның "әле хатаны төзәтергә соң түгел" дигәненә каршы: "Кәчән сүз кирү кәлмәз", - ди.

Йагъкуб сөйләмендәге мәкальләр исә зирәк картның, кайгы эчендә югалып калмыйча, улын күрәчәгенә өмет өзмәвен чагылдыра.

Шул рәвешле, Кол Гали үзенең киң карашлары һәм талант көче нәтиҗәсендә гаять җаваплы һәм читен иҗади бурычны хәл кылган: инде Шәрекъ дөньясында күптән оешып җиткән сюжетка яңа тормыш көче биргән, оригинальлек дәрәҗәсе югары булган әсәр барлыкка китергән.

***Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,***
***Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының җәмәгатьчелек белән багланышлар буенча директор урынбасары***

# "ДУМ РТ ХАДЖ" – ТАТАРСТАН МӨФТИЯТЕНЕҢ ХАҖ ПРОГРАММАСЫ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

гадәттә хаҗга өлкән яшьтәге кешеләр бара, ә алар аеруча игътибарга мохтаҗ.

Мина һәм Гарәфәдә хаҗиларны урнаштыру буенча килешүләр төзедек. Бу юлы палаткаларда җиңел матраслар, шулай ук кайнар эчемлекләр булачак. Тагын бер яңалык - Җиддә яки Мәдинәгә Казаннан турыдан-туры самолёт булачак. Элек Төркиядә күчеп утырырга туры килә иде.

**- Хаҗиларның куркынычсызлыгы турында сөйләп китсәгез иде.**

- Хаҗиларның теләсә-нинди сорауларына җавап бирә алучы югары квалификацияле гидлар булудан тыш, быел без хаҗиларга Согуд Гарәбстанының сим-карталарын таратачакбыз. Бу хаҗиларга туганнары белән элемтәдә торырга һәм югалмаска булышачак. Һәр хаҗига караңгыда янып торучы **"ДУМ РТ ХАДЖ"** эмблемасы сугылган букчалар биреләчәк.

Хаҗиларга Россиядәге һәм Согуд Гарәбстанындагы "кайнар элемтә" телефоннары биреләчәк.

**- Хаҗ кылуның бөтен үзенчәлекләрен барыбыз да белми. Хаҗиларны өйрәтәчәкләрме?**

- Без юлга чыкканчы ук лекцияләр укыйбыз. Моннан тыш, һәр хаҗига сәгатьләп язылган хаҗ программасы биреләчәк. Бу адашкан хаҗиларга аларның төркемнәре кайда булуын белергә ярдәм итәчәк. Лекцияләрне Казанда һәм Россиянең башка өлкәләрендә үткәрәбез.

Казанда гид-консультант командасы оеша. Хаҗ турында күбрәк белергә теләгәндә хаҗилар **"ДУМ РТ ХАДЖ"**ның консультация бүлегененең "кайнар элемтә" телефоннары аша белә ала.

***ТЕЛЕФОННАР:***
***Казанда: +7 (843) 524-92-10, 89662405398.***
***Мәскәүдә: +7 (985) 410-90-81.***

# Кавемен белгән диненнән, теленнән, милләтеннән ваз кичмәс

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Шәкертләр авыл районнарында практика үтеп торалар, гает намазлары укыталар. Алар хакында безгә яхшы гына хәбәрләр килеп тора. Шәкертләр практикага киткәндә аларга барган якларын ныклап өйрәнергә, элеккеге булган имам-мөәзиннәрнең, үзләренең нәсел-нәсәпләрен өйрәнергә кушып җибәрәбез. Килгәч алар безнең алда бу темалар буенча имтихан тота, сөйләп бирә. Бу үзенә күрә бер тәрбия чарасы булып тора.

Үзенең кемлеген - кем нәселеннән, нинди нәселдән, кавемнән булуын, ата-бабаларын белгән кеше беркайчан диненнән, теленнән, милләтеннән ваз кичмәячәк, беркайчан чит тәэсирләргә бирелмәячәк. Без мәдрәсәдә менә шул юлны истә тотып эшлибез дә. Булачак имамнарның туган телебезне, милли тарихыбызны тиешле дәрәҗәдә белүе, татарча вәгазь сөйли белүе мөһим дидек. Тагын бер мөһим чарабыз турында әйтеп узасы килә.

Безнең мәдрәсә әһелләренең күркәм гадәтебез бар: ел саен 2 май көнне Яңа бистәдәге Иске татар зиратында, кунаклар чакырып, остазларны искә алабыз. Чарага берничә көн кала шәкертләр белән каберстанга барып, мәрхүмнәрнең кабер өсләрен чистартып кайтабыз.

Гадәттә искә алырга килүчеләр - чараны оештыручылар һәм кунаклар - дин әһелләре һәм зыялылар зиярат итүне Габделхак Саматов кабереннән башлыйбыз. Советтан соңгы чорда башкалабызда ислам мәгарифе системасына нигез салган, Чистайдагы мәдрәсәсен Казанга күчереп, Исхак хәзрәт Лотфуллин белән бергәләп, Кабан арты мәчетендә дин гыйлеме бирүне оештырган мәшһүр хәзрәт иде ул. Соңрак Мәрҗани мәчете имамы, ТР Дания нәзарәтенең баш казые булып торганда да ихласлыгы, риясызлыгы, дин юлындагы фидакарьлеге тамчы да кимемәде аның. Икенче булып тукталган Габделхак хәзрәт Каюмов исә, имам булып эшләмәсә дә, совет хакимияте елларында, кая чакырсалар шунда барып, кача-поса дигәндәй, теләгәннәргә дин нигезләрен, гарәп язуын өйрәткән хәлфә бабай иде. Аннан совет хакимияте елларында курыкмыйча дин гыйлеме тараткан Габделхак Садыйков белән Габделхак Хафизовны искә алабыз. Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин, Әхмәтһади Максуди, Галимҗан һәм Салихҗан Барудилар, Габделхәбир хәзрәт Яруллин, Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрнең дә баш очларында Коръән аятьләре укып, дога кылып мәшһүр бабаларыбызның рухларын сөендерәбез.

Быел бу чараны җиденче ел рәттән уздырдык. Бүгенге шәкертләргә, мәдрәсәне тәмамлап хәзер үзләре имамлык итүче егетләребезгә гыйбрәт, үрнәк булсын дип тә оештырабыз моны. Әгәр бу фидакарь затларыбыз булмаса, бүген болай җыела, дин гыйлемен буыннан-буынга тапшыра алмаган булыр идек. Искә алу мәҗлесенә килгән олы кунаклар - Ульян өлкәсе мөфтие Сәүбан хәзрәт Сөләйманов, Ханты-Манси автономияле округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов, Самара өлкәсе мөфтие урынбасары Талип хәзрәт Яруллин, ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, Казан, Мамадыш, Апас, Тәтеш, Балтач имамнары, мондый күркәм чара һәр төбәктә, һәр мәхәлләдә үткәрелергә тиеш, дип таралыштылар. Моны гадәткә кертергә кирәк, җәмәгать. Чынлап та, һәр төбәктә дини мәгарифне җәелдерүгә хәленнән килгән кадәр өлеш керткән, үз ягында армый-талмый халыкны үгетләп, нәсихәтләп торган хәлфә бабайларыбыз, акъәбиләребез гомер сөргән бит. Аларны шулай хәтердә яңартып тору үзебез өчен дә, үсеп килүче яшь буыныбыз өчен дә мөһим.

Шәкертләребез дини тәгълиматны үзләштерү белән бергә кичке мәктәптә укып, дөньяви белем буенча өлгергәнлек аттестатына да ия була. Ахыр чиктә безнең бурыч - милләтебезгә фидакарьләрчә хезмәт итәрдәй зыялы кешеләр - дин әһелләре әзерләү. Безнең иң зур таләбебез - шәкертләр мәдрәсә программасындагы фәннәр белән генә чикләнеп калмыйча, дөньяви югары уку йортларында да укуларын дәвам итсеннәр, гомер буе гыйлем, мәгърифәт юлыннан барсыннар иде. Без шәкертләргә дини гыйлем биреп кенә калмыйбыз, аларны дөньяви фәннәр буенча да төпле әзерләргә тырышабыз. Компьютер классы булдырып, информатика фәнен укытабыз. Дәресләрдә төрле программалар кулланырга өйрәтәбез. Аларның күбесен дини һәм милли мәнәфәгатьләрдә куллану бик мәслихәт булыр иде. Ике нәсел агачын төзү программасы турында сөйләп узасым килә. Иң әһәмиятлесе - алар татар телле программалар.

Атаклы татар программалаштыручысы Зөбәер Мифтаховның матур гына "Нәсел агачы" дигән программасы бар. Ул тулысынча татар телендә. Программага туган-тумачаның, дус-иш һәм танышбелешләрнең исемнәрен, туган(-үлгән) елларын һ. б. белешмәләрен кертеп, ата-аналарына һәм балаларына "тоташтырып", электрон "Нәсел агачы" төзергә мөмкин. Килеп чыккан "Нәсел агачы"ндагы һәрбер исемгә "тычкан" белән ике кат чиртсәң - секунд эчендә шул исемнең үз "Нәсел агачы" ясала. (Уртада - шул кеше, сулда - ата-бабалары һәм әни-әбиләре, уңда - балалары һәм арырак токымнары.) Белешмәләр курсор астындагы исемнән бер читтә языла, курсор күчкәч сөртелә.

Берьюлы берничә аерым "Нәсел агачы" да булырга мөмкин, аларның тоташуы мәҗбүри түгел. Кирәк икән - бөтен авылыгызны язып чыгыгыз... Исемлектән берәр кешене күрсәтүгә, шуның "агачы" килеп чыгар, бөтен нәсел-нәсәбе белән бергә...

Бу программа бигрәк тә компакт, матур күренешле, "оператив" һәм максатка ярашлы булуы белән аерылып тора.

Тагын Дмитрий Киркинский ясаган программа бар - ул да Зөбәер Мифтаховныкына бик охшаган. Бик кулай һәм отышлы программа. Тулысынча интерфейсы татар теленә тәрҗемә ителгән. Без бу программаны мәдрәсә шәкертләренә өйрәтеп карадык. Моны безнең мөгаллим Зөлфәт Мингалиев башкарды. Шәкертләр информатика дәресендә бу программада нәсел агачларын төзеделәр. Кызыксыну көчле иде һәм кайсылары нәсел агачын төзүдә ярыйсы гына алга киттеләр. Инде безнең максат - нәсел агачын төзүне даими фән итеп мәдрәсәнең укыту программасына кертү. Бу киләсе уку елыннан башкарылачак. Әгәр мөмкинчелек булса, мин моны барлык мәктәпләрдә дә кертер идем.

"Әгәр үлгәч тә искә алсыннар дисәң, игелекле нәсел һәм эчтәлекле китап язып калдыр", - дигән борынгы акыл ияләре. Барыбыз да китап яза алмыйбыз, ә менә нәселебез дәвам итүчеләргә күркәм тәрбия биреп һәм аларга мирас итеп нәсел шәҗәрәсен язып калдыра алабыз.

***Ильяс хәзрәт ҖИҺАНШИН, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең гомуми бүлек мөдире***




**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница - с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00, вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата. Тел. 297-28-90**

Реклама





## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 23.06.12 | 2:29 | 3:59 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| *Якшәмбе* | 24.06.12 | 2:29 | 3:59 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| *Дүшәмбе* | 25.06.12 | 2:30 | 4:00 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| *Сишәмбе* | 26.06.12 | 2:30 | 4:00 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| *Чәршәмбе* | 27.06.12 | 2:31 | 4:01 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| *Пәнҗешәмбе* | 28.06.12 | 2:31 | 4:01 | 13:02 | 18:42 | 21:32 | 23:02 |
| *Җомга* | 29.06.12 | 2:32 | 4:02 | 13:02 | 18:42 | 21:32 | 23:02 |
| *Шимбә* | 30.06.12 | 2:33 | 4:03 | 13:02 | 18:42 | 21:32 | 23:02 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №25 (142) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-539.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 21 июнь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**